# Бакчада

**(әкият-тамаша)**



Низамиева Г.Р.

**Катнашалар:**

**Автор-башкаручы**

**Гайшә апа**

**Гөлсем апа**

**Яшелчәләр (кәбестә, суган, кишер, чөгендер, шалкан, укроп, кыяр, помидор, бәрәңге, кабак)**







**Автор.**

Язлар җиткәч эш башлыйбыз бакчада түтәлләрдә.
Яшелчәләр утыртабыз, төрле матур гөлләр дә.
Безнең ике күрше әби: Гайшә һәм Гөлсем апа,
Җир казырга керештеләр, кәсләрен вата-вата.
Гөлсем апа – тырыш апа, эшен ниргәләп башлый.
Гайшә апа – ялкау апа, бернигә эче пошмый.

**Гайшә апа.**
Кара, Гөлсем, ник ул кадәр көрәгеңне селтисең.
Җирне дөрес казымыйсың, эшнең рәтен белмисең.
**Гөлсем апа**.
Ярар, Гайшә, бик борчылма, үз эшемне җайладым.
Җир казу ысулларының иң яхшысын сайладым.

**Автор.**
Мырлый-мырлый Гайшә апа үз өенә юл тотты,
Гөлсем апа, эшен эшләп, аның сүзен онытты.
Җир казылган, вакыт инде хәзер түтәл ясарга,
Гөлсем апа саный, бүлә, карап тормый юк-барга.

**Гөлсем апа.**
Монда кишер чәчеп куям, монда чөгендер, шалкан,
Бу түтәлдә кабак булыр, анда кәбестә, суган.
Укропны да утыртырмын салатларга кушарга,
Витаминлы ризыкларны файдалы бит ашарга.

**Автор.**
Гайшә апа тагын чыкты бакчада казынырга,
Ничек кирәк шулай итеп түтәлләрне сызарга.
Урын әзер булгач ул да яшелчәләр утыртты,
Артык вакыт уздырмыйча, анда-монда таратты.
Гайшә апа күршесенә бакча серләрен сөйли,
Гөлсем апа  үз дигәнчә бакчасын тәрбияли.

**Гөлсем апа.**
Бәрәңгегә урын бик күп, анысы белән эш бетте.
Аңа кул да тидермәдем, трактор утыртып китте.
Инде бераз вакыт үткәч помидорлар күчердем,
Иртәрәк төртеп куйгачтын, кыярлар да тишелде.
И, минем яшелчәләрем, минем балакайларым,
Сөендереп үсәләр бит алар үз хуҗаларын.
**Автор.**
Җәй уртасы, Гөлсем апа бакчада сулар сибә.
Күршесенең яшелчәсе дым булмаганга кибә.

**Кәбестә**.
Карагыз әле, дуслар, без үсәбез гөрләшеп,
Тигез матур түтәлләрдә бер-беребезгә терәшеп.
Ә Гайшә апаның бер дә кәбестәсе уңмаган,
Яфраклары сары, юка, ышанасыңмы, суган?
**Суган**.
Әйе, кәчән, син хаклыдыр, кечкенә кәбестәсе,
Зур, түгәрәк булыр өчен аңа сулар сибәсе.
**Кишер**.
Ни дисәң дә, суган дустым, ул бакчасын карамый,
Гайшә апа – ялкау апа, аңа ничек тә ярый.
Хәтта кишер түтәлләрен озын буйлы чүп баскан,
“Күрше, бүген эссе”, - дип, ул чүпне утамаган.

**Чөгендер**.
Чөгендерне карагыз сез, шәлперәешеп беткәннәр,
Арасында да шулай ук үсеп беткән үләннәр.
**Шалкан**.
Я, әйт инде, чөгендер дус, шалканы уңган микән?
Якынрак барып карасаң, борча басмаган микән?
Гөлсем апа караса да, бөтен җирем кычыта.
Нинди генә агу табыйк ул бөҗәккә карата?!
**Кәбестә**.
Әйе, аңлыйм хәлләреңне, миндә шундый ук яра,
Сезгә генә сиздермәдем, аның төсе дә кара.
Үзе оча да, сикерә, яфракка менеп бара,
Беркемнән дә курыкмыйча ашый-ашый утыра.

**Укроп.** Мине укроп дип атыйлар, тәмләткечләр рәтеннән.
Ел саен чәчмәсәләр дә, үзем белеп тишеләм.
Минем үземне дә кайчак борчый яшел бөҗәкләр,
Шул бөҗәкләр аркасында ешрак тибә йөрәкләр.

**Бәрәңге.** Мине бәрәңге кортыннан ничә кат дәвалады,
Чүпләде дә, сиптерде дә, агу да салгалады.
Гөлсем апа бик тырышып теләгенә иреште,
Инде мин дә сау-сәламәт, балаларым җитеште.

**Кыяр**. Мин дә җитештем, эчемдә орлыгым тулып тора,
Гәүдәләрем яшелләнде, салатка әзер тора.
Әле мине тозлыйлар да, кисмәкләргә тутырып,
Кышның салкын көннәрендә ашар хуҗа утырып.

**Помидор**.
Мактана да, мактана бу; беләсең килсә, дустым.
Сине генә тозламыйлар, мин дә бар әле тагын.
Кып-кызыл булып җитешкәч өйгә алып баралар,
Ашка, боткага, салатка мине турап кушалар.
**Кыяр**.
Ярый-ярый, шапырынма, әнә ничек бүртендең,
Шартлый күрмә, бик күпереп калкып чыгар бүсерең.
**Помидор**.
Көнләшәсең, картлач кыяр, миннән күзең алмыйсың,
Шуңа күрә каршы әйтеп, әллә ничек карыйсың.

**Кабак**.

Я ле, дуслар, талашмагыз, туктагыз, дим, хәзер үк.
Бакча ямен бетерәсез, тавышланмагыз берүк.
Һәрберебез дә файдалы мәтдәләр туплаганбыз,
Нинди дә булса ризыкка барыбыз да ярарбыз.
Миннән бәлеш тә ясарлар, боткага да кушарлар,
Хуҗабыз оста пешерсә, “искиткеч”, - дип ашарлар.

**Кәбестә**.

Мин дә пирог пешергәндә бик тәмле эчлек булам.
Голубцы, салат, ашка да хәтта кушыла алам.

**Шалкан**.

Мин үзем дә витаминлы, яраткан кешеләргә.
Юкка гына кертмиләрдер мине әкиятләргә.

**Суган**.
Мин күз яше чыгарсам да, бөтенесен дәвалыйм.
Нинди ризык пешерсә дә, хуҗам мине салгалый.
**Кишер**.
Үсәсе килгән кешегә мине тәкъдим итәләр.
Минем сок та файдалы дип балаларга бирәләр.
Кыздырып ашка салалар, салатларга турыйлар.
Пюрелар да, икралар да кыландырып карыйлар.
**Чөгендер**.
Мин кып-кызыл, түп-түгәрәк, шуба, борщ һәм винегрет,
Ничек кенә пешерсәң дә, миннән бесподобный нет.

**Помидор**.
Борщ дигән ашка мине дә Һәрвакыт чакыралар,
Төрле ботка эзерләгәч, тоз сибеп тә ашыйлар.
Яз көннәрендә бигрәк тә була авитаминоз.
“Каян помидор алырга?”- килеп туа зур вопрос.
**Кыяр**.
Кыярны да кышлар үткәч бик тә килә ашыйсы,
Свежий кыяр исе чыкса, әллә каян танысың.
Тозлаган чакта да мине кайберәүләр капкалый,
Ашарга ризык булмаса, тозлы кыяр да ярый.

**Бәрәңге**.

Әле дә ярый бәрәңге бар, дип кешеләр куана.
Мин күп уңыш биргән чакта, менә алар шатлана.
Миннән боламык ясыйлар, мичтә тәгәрәтәләр,
Ярып, турап кыздыралар һәм суда пешерәләр.

**Яшелчәләр**.

Эйе, эйе, бәрәңге дус, синсез берничек булмый.
Сине бер көн ашамаса, кеше тамагы туймый.
Бәрәңгене без зурлыйбыз, бәрәңгегә җыр җырлыйбыз.
Кушылыгыз барыгыз да бәрәңге ашаучылар.

(Җыр башкаралар бәрәңге турында)

**Автор**.
Гөрләп ямьле җәйләр узды, көзге көннәр дә җитте.
Гөлсем апа бакчасында яшелчәләр җитеште.
Күрегез сез, ни генә юк бу оҗмах бакчасында!
Җаныгыз ни теләсә дә, таба аласыз монда!
Гөлсем апа  бакчасына уңыш җыярга чыкты.
Гайшә апа да үзенең бакчасына юл тотты.
Ялкау Гайшә апаның да бакчалары гөрләгән.
Яшелчәсен узып китеп дулкынлана зур үлән.
**Гайшә апа**.
Кайсы яктан тотынырга, башта нәрсә җыясы?
Кайда кабак, кайда кишер, ничек соң аерасы?

**Автор**.
Тиз арада йолкып чыкты барысын Гайшә апа.
Мул уңыш күренмәсә дә, ул үзенекен сата.
**Гайшә апа**.
Минем якта яңгыры да быел бик шәп булмады.
Шуңа күрә яшелчәм дә елдагыча уңмады.
Кортлары да бик котырды, әллә эссе килеште.
Алай дисәң, синекеләр әнә ничек җитеште.
Чүп үләнен әйтер идем, кая карап үскәннәр.
Кем аларны утырткан ди, миннән узып киткәннәр!

**Гөлсем апа.**
Борчылма, күрше, ул кадәр, минем якка карале.
Кәбестә, кишер, чөгендер, помидор да бар әле.
Ярып бәрәңге пешердем, кәбестә ашы әзер.
Төрле яшелчәләр турап, салат ясармын хәзер.
**Гайшә апа.**
Кабак бәлеше парланып өстәлеңне тутыра.
Әллә нинди тәмле исләр ул чыгарып утыра.
**Гөлсем апа**.
Әйдә, дустым, түрдән уз, ялындырма, күршекәй.
Менә монысын авыз ит – яңа пешкән ипекәй.

**Автор**.
Шулай гына була ул, җәйли бик күп  үстерсәң.
Кыш көнендә ач булмассың, төрләндереп пешерсәң.
Ялкау кешегә кызыкма, аның уңышы сирәк.
Эш кешене бизи диләр, эшне сөяргә кирәк.

(Көз турында җыр башкаралар)